**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР №20**

Димтамак ав. 29.08.2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы 11 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсендәге 3 бүлеге, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Россия Федерациясе Федераль законы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы «Җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы 11 санлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсендәге 3 бүлеге, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Россия Федерациясе Федераль законы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:»;

1.2. Карарның 2, 3 бүлекләрен төшереп калдырырга;

1.3. 4, 5, 6, 7 бүлекләрне 2, 3, 4, 5 бүлекләр дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов